# КЫЗЫКЛЫ ДА, ГЫЙБРӘТЛЕ ДӘ

«Үзара макташулардан, куштанлыклардан сөрсегән, югары пафослы нотыклар тыңлый-тыңлый тынчыган, таркалу чигенә җиткән җәмгыятьне бары тик сатира гына сафландыра, коткара ала» дигән тәгъбир бала чагымда ук башыма сеңеп калды. Ә инде туры сүзне, гадел фикерне, тәнкыйтьне читкә тибәргән, ялган сәясәт белән яши-яши үзәгенә кадәр черегән, сатирикларын эзәрлекләп җәфалаган дәүләтләрнең җимерелеп, таркалып бетүләрен үз гомеремдә күп мәртәбәләр күрдем.

Фәнзаман Батталның көндәлек матбугатта өзлексез чыгып килүче чәчмә һәм шигъри әсәрләрен, публицистик язмаларын, китапларын укыганда, һәрвакыт әлеге фикерләр, илкүләм бихисап фаҗигаләр зиһендә кабат яңара… Моннан егерме ел элек, аның, ягъни Ф. Батталның, иҗатын ныклап анализлау, бәяләү максаты белән «Сатира батыры» исемле зур күләмле мәкалә язганым һәм аны «Казан утлары» журналында бастырганым да бүгенгедәй истә. Анда мин: *«Чын сатириклар сирәк туа… Бөек Тукайны, Гамил Афзалны искә төшерүгә үк, Фәнзаман Баттал исеме хәтергә килә»*, — дигәнмен дә аның сәясәттә алдан күрү сәләтен, шул сәләте белән замандашларыбызны күп мәртәбәләр сискәндерүе, дөньяга ачык күз белән карарга ярдәм итүе, фикердәшләрен һәм… дошманнарын арттыруы, үзенә бихисап кыен ашатулары, Тукай рухлы әдипнең барыбер гадел, туры сүзле, ихлас иҗатлы булып калуы, чорыбызның сатира батыры булып танылуын исбатлаганмын. Һәм ул фикеремдә хәзер дә нык торам.

Хәер, тора-бара аның шундый ук сыйфатларын дистәләрчә башка әдипләребез, зыялыларыбыз да күрә белделәр, иҗатына зур бәя бирделәр. Публицист Ислам Әхмәтҗанов аны «азатлык максатында ахыргача бара торган зат» дип бәяләсә, танылган әдип Айдар Хәлим исә «әдәбиятыбызга, милләтебезгә Аллаһ тарафыннан иңдерелгән кадерле бүләк» фикерен бөтен татар дөньясына матбугат аша җиткерде. Шәрәфле академик, педагог, язучы-публицист Мәхмүт Әхмәтҗановның да бәясе үзенчәлекле һәм гыйбрәтле. Ул, Фәнзаман Баттал иҗатын гомере буе күзәтеп, җиз иләктән үткәрә-үткәрә өйрәнгәннән соң, бу әдип иҗаты турында күләмле мәкаләләр бастырды һәм мондый нәтиҗәсен дә әйтеп калдырды: *«Әдәбият тарихы турында сүз чыкса, даталар да кулланмыйча гына, «Тукайлар дәверендә», «Исәнбәтләр чорында…» кебегрәк сөйләү, язу гадәтебез бар. Минемчә, соңгы чирек гасыр турында сүз чыкканда, килер буыннар аны «Фәнзаманнар заманы» дип йөртерләрдер. Бу язучыбыз ул мәртәбәгә күптән лаек».*

Болганчык сәясәтле, барыр юлы да мәгълүм булмаган илләрдә, патшалары, җитәкчеләре дистә еллар буе тәхеткә ябышып ятарга күнеккән, диктаторларга әверелгән дәүләтләрдә

сатирикларны, туры, гадел фикер әйтергә җөрьәт итүчеләрне хакимиятнең «үги уллары», дошманнары дип тамгалыйлар. Шөкер, соңгы елларда Татарстаныбызда андый ук галәмәтләр сизелми башлады. Фәнзаманны да судлар, милицияләр юлында йөртүләр, прокуратура допросларына кат-кат чакыртулар тукталып тора сыман... Алай гына да түгел, соңгы өч-дүрт елда гына да Язучылар берлеге аның үткен сатирасын, һәр укучысына көләчлек бүләк итәрдәй нечкә юморын югары бәяләп, үткән гасырның бөек тел остасы булып танылган Фатих Хөсни, Тукай сатирасының дәвамчысы булган Гамил Афзал премияләренә лаек дип таптылар. «Казан утлары» журналының сатирик әсәрләр конкурсы нәтиҗәләре буенча да җиңүчеләрнең берсе буларак бәяләнде Фәнзаман Баттал.

...Инде менә кулыбызда язучының яңа җыентыгы. Китапның «Аз-азлап кына...» дип исемләнгән булуы сәер тоелган иде башта. Аннары сәбәбе тиз аңлашылды: баксаң, үзе гомер буе «файдаланган» кайбер кызыклы, мавыктыргыч жанрларыннан аз-азлап кына иҗатының үрнәкләрен җыеп тәкъдим итәргә ниятләгән икән бу юлы. Монда гап-гади көнкүреш темаларына язылган җыйнак күләмле юморескалары да, гыйбрәтле язмышлар чагылыш тапкан саллы әсәрләре дә урын алган.

Яшәеш мохитебездәге шактый кешеләрдән: «Сәясәт катлаулы нәрсә ул. Без аны аңламыйбыз», — дигән сүзләрне еш ишетәбез. Чөнки чит ил сүзләре дә шыплап тутырылган, рәсми тел белән язылган мәкаләләрне укыганда, башыңдагы миең урынына чуерташлар тутырылгандай була... Ә инде Фәнзаманга гына хас җор тел белән язылган, шушы китапта да урын алган сәяси язмалар һәркемнең зиһене җиңел кабул итәрлек. Мәсәлән, сәяси темага язылган бер язмасы «Песи баласын сагынганда...» дип исемләнгән. Һәм, чыннан да, чирләшкә песи баласының фаҗигале үлеме турында гына кебек тоела ул әүвәл... Ләкин, эзлеклелеген һич тә югалтмыйча, дөньякүләм коточкыч фаҗигаләрнең сәбәпләрен ачуга, тәфсилле анализлауга барып тоташа һәм укучы белән киңәшү рәвешен ала... «Үзгәртербез дөньяны!», «Алтын миллиард», яхуд артык тамаклар» дигән язмалары да җитди темаларга иҗат ителгән булуларына карамастан, кызыклы хикәяләрдәй җиңел укыла. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: аның публицистикасы тарихи документларга, төрле галимнәрнең, ил башлыкларының, сәясәтчеләрнең төгәл күчерелгән цитаталарына таяна.

Әйе, Фәнзаман Баттал бу китабын да башыннан ахырына кадәр укучысын «кулыннан ычкындырмаслык» кызыклы да, гыйбрәтле дә әсәрләреннән төзегән. Аның дөньяга чыгуы укучыларыбыз өчен якты да, күңелле бәйрәм булыр сыман. Бирсен Ходай!

*Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ,*
*әдәбият тәнкыйтьчесе*



# ТӘМУГТАН СОҢ – ОҖМАХКА

*Бу китабымны үткен телле, гадел күңелле газиз әнкәм Миңнебәдәр Бәхтегәрәй кызының 100 еллыгына багышлыйм.*

## КҮКӘЙ БӘЛЕШЕ

Галимҗан белән бакча күршеләре без. Әйе-әйе, мактаныбрак сөйләшкәндә, «дача күршеләре» дип җиффәрәбез. Дача икән, димәк, ял итә торган урын була инде ул. Тик шунысы бар: анда ял итеп кайткач, ике-өч көн буе үзеңне бөкре кол итеп сизәсең. Билләр сызлый, кулдагы яңа сөялләр үзәккә үтә. Сөял дигәннән, үзебез генә түгел, көрәкләребез дә, балта-пычкыларыбыз һәм кәтмәннәребез дә туганлашып беткән инде безнең.

Ә-ә... Әле шушы дачаларыбызга җир алган көн искә төште. Кишәрлекләребездә межага бау тарттырып чөйләр каккач һәм дә көрәкләребез белән ике араны яргач, үз ягыннан Галимҗан дәште:

— Эш качмас ул, күрше, иртәгә дә көн бар. Бүгенгә кайтыйк, минем фатирда чиратлашып ванна кереп алыйк. Сөякләр йомшарып китәр... — Аннары мәгънәле генә итеп күз кысты да тамагына чиртеп алды. — Берике сәгатьтән хатын эшкә китәргә тиеш. Чәкешә-чәкешә, иркенләп гөрләшербез.

Иярдем. Галимҗанның хатыны кояштай балкып каршы алды. Залга үттек, һәм мин шунда, кем әйтмешли, телсез калдым. Йа Хода! Өстәл тулы китап! Юк, дөрес аңлагыз, мин китап күрмәгән егет түгел, мәгәр бу дөньяда мондый китаплар коллекциясе бардыр дип башыма да килгәне юк иде. Алтмышлап китап өелгән һәм шуларның һәркайсы аш-су әзерләү турында! «Кулинария серләре», «Тәмле ризыклар пешерергә өйрән», «Гөмбә ашлары», «Балык ашлары», «Бәйрәм өстәле», «Тәм-томнар», «Бәрәңгедән мең дә бер ризык», «Йомырка ашлары»...

Һи-и, мин дә хатын бар дип яшәгән булам бит, ходавәндә!.. Минем Шәмсиянең бар белгәне бәлеш тә өчпочмак, кыстыбый да коймак, пылау да пилмән... Гөбәдияләр, юкалар, кәтлитләр пешереп, ис чыгарып, көн саен плитә тирәсендә кайнашкан була инде тагы...

Ә монда кытай, япон ашлары, чукча, чуваш, мари кулинариясе... Галимҗанның хатыны Рәмзия үзе дә шул китаплар уртасындагы гөл кебек. Китаплар белән кызыксынуымны, аларга карап хәйран калуымны сизгәч, канатланып китте.

— О, кулинария китаплары әнә теге шкаф тартмасында да күп әле. Мин үзем меңнәрчә ризык рецептларын беләм. Аш-су китабын күрсәм, айлык хезмәт хакым да җәл түгел, валлаһи, — дип сүз башлады ул һәм өстәлдән кирпечтәй калын, күз явын алырлык китапны күтәрде, маникюрлы нәфис бармаклары белән актара-актара, әле бер, әле икенче сурәтне күрсәтергә кереште:

— Татар халкының менә бу ризыкны төшендә дә күргәне юк, беләсегез килсә! Ә монысы — итальян кулинарларының яңа казанышы. Күрәсезме, дерелдәвек эчендә калдырган күркә ите нинди зәвык белән киселгән. Пешереп туралган күкәй... сездә ничектер, бездә авыз бөрештереп, культурный кыланып, «йомырка» дип тормыйлар, «күкәй» диләр... менә, күрегез, ничек матурлый ризыкны!

Дөресен әйтми кала алмыйм, гайбәттән булмасын, иллә дә мәгәр Галимҗанның тәртибе, үз-үзен тотышы ошамады миңа ул минутларда. Хәләл җефетенең очынып-очынып сөйләвенә кинаяле елмаю белән йөзен чытыбрак карап торды да:

— Ярый, сез сөйләшә торыгыз, мин ваннага беренче булып керим, булмаса, — дип, залдан гаип булды.

Рәмзия, шуны гына көткән кебек, тагын да дәртләнебрәк аңлата башлады:

— Нигериядә иң абруйлы ризык хакында беләсегез киләме?.. Согуд гарәпләренең кунакларга гына пешерә торган ашлары турында сез хәбәрдармы?.. Борынгы һиндләр кулинариясеннән нинди ризыклар авыз иткәнегез бар?..

Менә бит хикмәт! Ул сөйли тора, ә мин Британия короленең нинди ризыклар яратуын, Мисыр фиргавеннәренең нәрсәләр белән тукланып гомер кичергәнлекләрен, Бен Ладенның, сакалын сыйпый-сыйпый, нинди ризыклар белән туклануын тыңлап утырам!